

Казан (Идел буе) федераль университеты
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты
Габдулла Тукай исемендәге
Татаристика һәм тюркология югары мәктәбе

# Раушан

*Студентлар газетасы*

08.05.2017



## Сызлыйдыр һаман да яралар...

**Үкереп елыйдыр Җир-ана,**
**Елыйлар каеннар сыгылып.**
**Күкләргә тынычлык китергән**
**Баһадир улларын сагынып.**

**Күзләрдә бер сорау: "Кайда Сез?"**
**Китмисез беркайчан күңелдән.**
**Хәбәрсез югалган күбесе,**
**Күбесе чит җирдә күмелгән.**

**Без баскан җир өстен, белегез,**
**Күпме яшь сугарган, күпме кан.**
**"Туган ил өчен", дип җан биргән,**
**Киләчәк өчен, дип чыдаган.**

**Әнә, күр! Бер сафка тезелеп,**
**Җиңүче Солдатлар баралар.**
**Күзләрдә ачы яшь һәм шатлык.**
**Сызлыйдыр һаман да яралар...**

**Ләйлә Хәбибуллина**
**9 май 2013**

- **СССРда 43миллионнан артык кеше һәлак булган дип исәпләнә. Германиядә исә бу күрсәткеч 2миллион.**
- **Сугыштан соң СССРда Җиңү көнен унҗиде ел узгач кына бәйрәм итә башлыйлар.**
- **Сугыштан соң СССРда 127миллион кеше генә кала. Ленинград блокадасы 872 көн бара.**
- **Бөек Ватан сугышында ир-атлар гына түгел, хатын-кызлар да көрәшкән.**
- **Сугышта 60 меңнән артык эт катнаша.**
- **Мина эзләүче этләр 300дән артык шәһәрне коткарып калалар.**



## КАНӘФЕР АГАЧЫ

**Тирә-якка хуш ис беркелә. Дөньяның әле җанланып, уянып кына килгән вакыты. Иң әйбәт вакыт дип әйтер идем. Бу вакытта урамнар тын, ә мин − тынлык, тынычлык сөюче. Шау-гөр килгән төркемнәргә дә кушылмыйм, үзем генә үз уйларымны чын итеп, хыялланып йөрим. Ә яраткан вакытым минем − май ае. Ул бит чәчәкле, гөлле ай, бөтен әйләнә-тирә ап-ак чәчәкләргә күмелгән вакыт. Мин бигрәк тә бу вакытта канәфер чәчәкләренә сокланам. Бу серле агачның һәр үсентесендә ничәмә кечкенә чәчкә, алар бер-берсенә искиткеч охшаш шикелле. Ләкин алай түгел. Һәр чәчәкнең үз төсе, үз асылы.  Аларның һәрберсенә җан эрелгән, һәр чәчкәгә яшәү нуры бирелгән.**
**Һәр ел канәфер чәчәк атканын көтеп алам мин. Менә быел да бу йолдызларны  күрергә дип килдем. Канәфер агачы быел тагын да матур- матур чәчәкләренә җан өргән, урамга керүгә үк инде аның хуш исе башны әйләндерә. Елдан-ел ул матурлана, зифалана барган кебек тоела миңа. Монда тыныч, үзең дә сизмәстән хыял дөньясына чумасың.**
**Ничә ел инде мин канәфер агачы янына йөрим. Бөтен хыялый минутларым, иң бәхетле чакларым да минем бу агач ботакларына кунып, аякларын салындырып җиргә шагыйрәнә нур агыза. Күпме генә монда йөрсәм дә, йөреп туя алмам кебек. Мин генә түгел, күп кешенең юлы канәфер агачының тамырлары назланган сукмакка тоташа. Кемдер ерак калган яшьлеген искә төшерә, кемдер илһамланып шигырь яза, берәүләр ял вакытларын хуш исләр шәленә чорналып үткәрә.**
**Кайчан гына бу агач янына килсәм дә, кулларында канәфер яфракларын тирбәтүче, назлаучы бер бабай утырганын күрәм. Аның күзләрендә сагыш, бушлык. Килгән саен сүз башлыйсым килә, тик нигәдер кыюлыгым җитми, аякларым атламый башлый. Тик бүген түзәр чамам калмады: карт белән нәрсә булганын беләсем килде минем. Аякларым да мине шунда илтә, күңелем дә бишек җырлары көенә нурга тартыла.**
**− Исәнмесез, утырырга мөмкинме? − дип атладым мин бабай янына.**
**− Мөмкин, кызым, утыр, утыр, − диде ул тыныч кына. Бераз тынып торгач:**
**− Син канәферләрне бик яратасың ахрысы? Һәрвакыт монда килгәнеңне күрәм.**
**− Әйе шул. Яратам, башка агачка бер дә охшамаган бит ул. Үзенә тартып тора.**
**− Әйе, кызым, мин дә аларны яратам. Аңардан нур беркелә. Тарих нуры. Күрәсеңме, агачның кәүсәсен кочаклап баскан кызны. Кулларында нәрсә уйната ул? Белмисеңме? Белерсең әле. Бәйли бит ул. Аяк очындагы хәтфә үләннәрдә йомшак керпеләр тәгәрәшә бит. Өскәрәк кара әле, әәәнәә, югарырак ботакка. Кызның баш очындагы баланы күрәсеңме? Әнә-әнә, канәфернең биш таҗлыларын чүпләп утыра. Эх, тәмләп авыз итә канәферләрне. Кояшта җылынган, назланганнарын гына ал! Колак сал әле, балам! Ишетәсеңме?  Җеп эрләнгән тавыш. Хәтфә үләннәргә кара. Әнә бит Әби җеп өрли. Канәферләрдән.**
**Мин як-ягыма карана башладым. Беркем дә юк, без монда ялгыз. Ят тавышлар да ишетелми.**
**− Минем яшьлегем канәферләр белән бәйле. Һәр чәчәгенә күңелемне кайнатып салдым. Хәзер җаным алар белән чәчәк ата, яши. – Бу сүзләр мине куркуга калдырды. Мин ни эшләргә дә белмичә, тын гына бабай янында утыра бирдем.**
**− Бабай, шул вакытларыгыз турында сөйләгез әле, − дип сораганымны сизмичә дә калганмын. Үзем канәфер агачына каранам. Бабайның кулларындагы яфракларны да күздән ычкындырмыйм.**
**- Ярый, кызым, тыңла.**
**( Дәвамы "Раушан" студентлар газетасы"ның ВКонтакте төркемендә )**



**Шиһапова Гелүсә,**
**1 курс магистры**

## АЛАР ДА БИТ СТУДЕНТ БУЛГАН



**Яз житте. Әлеге сүзне ишеткәч, эчебездәге ничәмә-ничә күзәнәгебезгә җылылык йөгерә бит. Ә исе борыннарга керү белән, күңелләребезне кытыклап, матурлык, җылылык, наз көтә башлый. Әйе, яз аеның җылы кочагында без үзебезне әнкәйләр куенында кебек рәхәт һәм тыныч хис итәбез. Вакыт-вакыт әлеге тынычлыкны бозарга омтылган курс эше һәм сессия хакында искә төшермәгәндә бигрәк тә. Һәм шул минутларда күп тапкырлар ишетергә туры килгән: “Тормышыгызның иң тыныч, проблемасыз, рәхәт мәле – студент вакытыгызның кадерен белеп калыгыз”, - дигән сүзләр искә килеп төшә. Һәм әлеге җөмләне безгә иң еш кабатлаучылар – ул, әлбәттә, безнең сөекле мөгаллимнәребез. Сорашып карыйк әле, бәлки аларның студент чорлары дөрестән дә күпкә мәшәкатьсез һәм күңеллерәк булгандыр...**

**Гөлназ Фоатовна:**

**“Студент елларын бик еш һәм сагынып искә төшерәм. Бөтенебез дә бер казанда кайнаганлыктан, кем курсларга, кем олимпиадага һәм конференциягә килгәнлектән, группадашларым белән еш очрашып торабыз. “WhatsApp”та аерым төркемебез дә бар, анда бик еш бер-беребезнең хәлен белеп, туганнар кебек кайгыртышып яшибез. Гомумән, мин музыкант яки математик булырга хыяллана идем. Мәктәптә укыган дәвердә үк математика тарихы белән кызыксынганымны хәтерлим. Галимнәр һәм аларның ачышлары хакында мәгълүматны туплаган дәфтәрем дә бар иде хәтта. Шулай ук музыка мәктәбендә дә укып чыктым. Консерваториягә укырга керү хакында да уйлар юк түгел иде. Бүгенге көндә дә яраткан шөгылемә тугъры кала бирәм – атнасына берничә тапкыр кулларыма баян алам, фортепьяно да шулай ук читтә калмый. Шулай да бүгенге көндә үз һөнәремне сайлаганга бер дә үкенгәнем булмады.**

**Бүгенге көн студентларына килгәндә, безнең заман белән чагыштырганда, аларны уку залларында, китапханәләрдә ешрак күрсәм, мин бик шат булыр идем. Сирәк чыганаклар, газета-журналларның интернетта булмаган шактый басмаларында да кызыклы һәм файдалы мәгълүматлар бик күп тупланган бит.**

**Минемчә, студент ул кызыксынучан, креатив, заманча фикерли торган, үз-үзенә таләпчән, максатчан, эзләнүчән булырга тиеш. Шул вакытта ул, һичшиксез, тормышта үзе куйган максатларга ирешә алачак”.**

**Флёра Сәгыйтовна:**

**“Безнең заманда студент тормышы вакыйгаларга бик бай иде. Багышлау һәм Студентлар язы кебек бүгенге көндә дә оештырыла торган чаралар белән беррәттән, без фольклор экспедициясенә дә бара идек. Шәхсән безнең төркемгә Әстерхан яклары белән танышу бәхете татыды. Әлеге экспедиция белән бәйле хатирәләр дөрестән дә бик кадерле, һәм аларны искә төшерәсе генә килеп тора. Шулай ук студактив оешмасының әгъзасы булу минем студент тормышыма якты буяулар өстәде дип әйтә алам. Безгә хәтта “Золотое кольцо” маршруты буенча Россиянең төрле шәһәрләренә сәяхәткә бару мөмкинлеге дә бирделәр. Анда күргән әйберләр бүгенгедәй хәтеремдә саклана. Студент үзен укуга гына бирергә тиеш түгел, төрле күңел ачу чараларына да йөреп, үзен эзләргә һәм камилләштерергә тырышса яхшы. Төрле чараларда үзен актив күрсәткән студентларга уку да җиңелрәк бирелә шикелле.**

**Ләйлә Ихсановна:**

**“Студент еллары һәр кеше тормышында аерым бер этап булып тора, һәм менә шул этапны үтә алган кешене мин бик бәхетле дип уйлыйм. Бүгенге чор белән чагыштырганда, безнең студент еллары бөтенләй башкача узды. Мин үзебезне шул чорда студент була алуыбыз белән бәхетле булганбыз дип саныйм. Иң җылы һәм йөзләрдә елмаю уята торган хатирәләр, әлбәттә, фольклор экспедициясе белән бәйле. Без төркемебез белән Пермьның Барда районына бардык. Биредә һәрберебез тормыш өчен дә, фән өчен дә бик күп яңалыклар ачты. Авыл халкы өчен концертлар куеп, татарча сөйләшеп, гөрләтеп кайткан идек.**

**Кайсы гына чор студентлары булмыйк, барыбызны да тормышта татырга насыйп булган олы бәхет – студент булу бәхете берләштерә. Мөгаллимнәребез кебек, тормышта үз урыныбызны табар өчен безгә барлык мөмкинлекләр дә бирелгән, киңәшчеләребез яныбызда. Тырышасы гына кала.**

**Айсылу Баһавиева, 2 курс**

## Истәлекле очрашу



**26 апрель – бөек Тукаебыз туган көнне – институтыбызның Г.Тукай исемендәге татаристика һәм тюркология югары мәктәбендә көтеп алынган, кадерле, бөтен төрки дөньяда, Рәсәйдә кыю һәм хөр фикерле милләтпәрвар шәхес буларак танылу алган мәртәбәле кунагын – Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, язучы Ринат Мөхәммәдиевнең «Күз ачкысыз буран» романын тәкъдир итү кичәсе булып узды. Кичәгә кадәр әдәбият укытучыбыз: «Менә күрерсез, аның зыялылыгына исегез китеп карап торырсыз әле», − дигән иде. Көтеп алынган мизгел җитеп, мәһабәт, тыйнак һәм шул ук вакытта үтә дә зәвыклы киенгән Ринат Мөхәммәдиев аудиториягә кергәч тә, башыма бары тик бер уй килде: «Дөрес әйткән, хак әйткән! Ә.Еники зыялылыгы, Мөһәммәдиевләр рухы сизелә».**

**Кичә Г.Тукай исемендәге татаристика һәм тюркология югары мәктәбе студентларының чыгышы белән башланып китте. Алып баручылар әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштырды, экранда фотосурәтләрдән «күргәзмә» тәкъдим ителде. Кунагыбызның, күзләрен түбән иеп, тыйнак кына тыңлап утыруына күз салгач, уйлар тәмам икенче якка авышты: картлык экранда күрсәтелгән яшьлек фотоларыннан карап торган егетнең бары чәчләренә генә кагылган төсле тоелды (кем белә, бәлки бу аның күңел чагылышы, шуннан күчкән аклык кынадыр), чөнки каршыбызда утырган кешенең күзләрендә шул ук көчле рух, ялкын һәм татар халкына хас тирән моң сизелә иде. Әдип белән таныштыру өлеше тәмамлангач, сүз Ринат Мөхәммәдиевнең үзенә бирелде.**

**Язучының бөтен кыяфәтеннән, үз-үзен тотышыннан аның гаҗәеп бер шәхес булуы күренеп тора иде, шунлыктан, бар аудитория, нәрсәне дә булса ишетми калудан куркып, тын да алмый, йотылып тыңлады. Ринат абыйның, Мәскәүнең биек йортларында яшәп тә, туган туфрагын, Мамадыштагы йөрәгенә якын булган яшел чирәмле Кече Кирмән авылын, Татарстанны, татарлыкны сагынуы һәр сүзеннән сизелеп тора иде.**

**Кичәбез Ринат Мөхәммәдиевнең иҗатына, төрки дөнья яратып кабул иткән «Күз ачкысыз буран» романына, әдәбиятка, милләткә кагылышлы сораулар бирү белән дәвам итте. Әдип, студентларның, уйлап һәм уйлап бетермичә, кызыксынып бирелгән һәр соравын, күңеле аша үткәреп, озак көттермичә генә җавап бирде. Сүзе аз – мәгънәсе шулкадәр тирән: сүз уйнату да бар анда, җан ачысы да, киная дә, фәлсәфә дә...**

**Ринат абый Мөхәммәдиев, зыялыларга хас тыйнаклык саклап, ана кеше газиз баласын назлагандай яратып, кадерләп үзенең һәр әсәре турында диярлек сөйләп чыкты: «Ак кыялар турында хыял» мине язучы ясады, мине Язучылар берлегенә кабул иттеләр. «Кенәри – читлек кошы» мине Татарстан Язучылар берлеге рәисе ясады. «Сират күпере» миңа дан-дәрәҗә китерде, Тукай бүләге, М.Шолохов бүләге, Азия-Африка илләренең алтын «Лотос»ын һәм Төркиянең әдәбият-мәдәният өлкәсендәге иң югары бүләген алуга китерде. «Утлы таба өстендә» ун тапкыр басылып чыкты. Ул дөнья буйлап иң күп таралган, 21 чит илдә басылган әсәрем булды. Туран Язган турындагы бу әсәрем минем өчен шәхес буларак онытырга ярамый, ташлап китәргә ярамый торган изге темага язылган, чөнки без хәзер шундый заманда яшибез.»**

**Кичә азагында әдәбият кафедрасы мөдире, филология фәннәре докторы профессор Әлфәт Мәгъсумҗан улы Закирҗанов йомгаклау сүзен әйтте, Ринат Мөхәммәдиевка рәхмәт белдерде.**

**Г.Тукай исемендәге татаристика һәм тюркология югары мәктәбендә, татар телле мохиттә үткәрелгән әлеге кичә Ринат Мөхәммәдиевка татар укучысының рәхмәте һәм ихтирамы булып яңгырасын иде.**

**Илүзә Гайфуллина, 3 курс**








## Иске яңа Тукай

**Казан федераль университетының “Tataristica” үзәге татар дөньясы өчен мөһим темаларга сөйләшүләрне дәвам итеп, 19 апрель көнне “XXI гасыр һәм Тукай” темасына дискуссия оештырды. Спикерлар арасында Разил Вәлиев, Хатыйп Миңнегулов, Рабит Батулла кебек аксакалларыбыз да, Рүзәл Мөхәммәтшин, Рәдиф Кашапов кебек талантлы яшьләребез дә бар иде.**

**Дискуссияне шагыйрь, ТР Дәүләт Советы депутаты Разил Вәлиев: “Тукай − үзе үк үзенә бәя биргән шәхес, аның шигырьләрен укыгач, кем икәнен аңлыйсың, ул артык тыйнакларны яратмый, чөнки артык тыйнаклык мокытлыкка илтә. Тукай бик горур кеше була һәм тартынмыйча Пушкиннар белән янәшә атлый. Тукайның бөеклеге – аның милләт язмышы белән яшәвендә”, − сүзләре белән башлады.**

**Иконадан брендка**

**Шагыйрь, ТРның Премьер-министры секретариатының баш референты Рүзәл Мөхәммәтшин: “Тукайдан икона түгел, бренд ясарга кирәк. “Тукай конфеты”, “Тукай сабыны”, Тукай портреты төшерелгән футболкалар чыгарылса, яхшы булыр иде”.**

**Татар яшьләре активисты Рәдиф Кашапов: “Тукай үлгәч, аның исеме белән конфет чыгара башладылар. Брендка әверелү шәхеснең чын сурәте халыктан ерагаюга китерә”.**

**Разил Вәлиев исә аңа җавап итеп: “Әгәр ул халыктан ерагайган булса, Тукай китаплары тузан җыеп ятар иде, ә чынлыкта, аларны кырып-себереп алып бетереп баралар, күптән түгел дөнья күргән “Тукай энциклопедиясе”н генә алыйк, аны хәзер бер җирдән дә табып булмый”. Сүз уңаеннан, 2017 ел башында дөнья күргән әлеге энциклопедиядә 2360 мәкалә урын алган, алар 25 ел дәвамында 137 автор тарафыннан язылып тупланган.**

**Шәхесне өйрәнгәндә детальләр мөһимме?**

**Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла: “Тукайның кайсы күзенә ак төшкәнен кем әйтә ала? Без бу шәхес турында вак детальләргә кадәр белергә тиеш”. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш гыйльми хезмәткәре, филология фәннәре докторы Зөфәр Рәмиев ярымшаяртып: “Монда ике генә вариант бар”, − дип җавап кайтарды.**

**“Тукайның кимчелекле якларын балаларга өйрәтү кирәкме?” соравына Разил Вәлиев болай диде: “Балага бит тууга теләсә нәрсә ашатмыйбыз, башта сөт эчертәбез, аннан соң гына әкренләп тозлысын-борычлысын бирә башлыйбыз. Бу очракта да шулай”.**

**Тукай ник үз музеена үзе сыймый?**

**Музей турында сүз кузгалгач, Разил Вәлиев: “Тукай музее бик кечкенә, анда Тукай сыймый”, − диде, шулай ук музейның төсе сары булуына ризасызлык та белдереп, “Аңа тора-бара “сары йорт” кушаматы берегеп калырга мөмкин”, − диде ул. Г.Тукай музее директоры Гүзәл Төхвәтова исә моның алардан тормавын, бинаның төсе, төзелеше архитекторлар тарафыннан хәл ителүен әйтте.**

**Тукай турында сөйләп сүз бетми, Батулла әйтмешли: “Тукай – яшенүткәргеч, ул, ике арага ятып, халкын коткарган кеше. Тукай – шәм, ул бездән ерагайган саен, ныграк яктыртачак”.**

**“Татар театры: югалту һәм табышлар” дип исемләнгән киләсе дискуссия 17 май көнне шул ук урында узачак.**

**Зилә Сабитова, 3 курс**

Баш мөхәррир – Халисә Ширмән Мөхәррир – Дамир Хөснетдинов
Иҗат коллективы: Алсу Сәлахова, Ләйлә Хәбибуллина, Гөлүсә Шиһапова, Айсылу Баһавиева, Илүзә Гайфуллина, Зилә Сабитова.
Биткә салу һәм дизайн буенча белгече – Диләрә Шакирова
Редакциянең фикере авторларның фикере белән туры килмәскә мөмкин.
Газетаны гамәлгә куючы − Казан (Идел буе) федераль университеты Л. Толстой ис. Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г. Тукай ис. тюркология һәм татаристика Югары мәктәбе
Редакция адресы: 420021, Татарстан ур., 2 , 127 бүлмә.
Хәбәрләшү өчен телефон: 89274019142 Электрон почта: raushantat@yandex.ru